**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР №32

Әбсәләм ав. 23 ноябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының
Әбсәләм авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 2 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.6.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.1. Сыйныф чинын бирү көне дип сыйныф чинын бирү турында карар кабул итү көне санала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева